ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

01 10 2021 г. № 849

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 апрелендәге 212 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территория-сендә өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыруның административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 апрелендәге 212 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыруның административ регламентына кертелә торган кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма матбугатта һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044487

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның «01» 10
849 номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 апрелендәге 212 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыруның административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1. 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Алар нигезендә дәүләт функциясе башкарыла торган норматив хокукый актлар исемлеге:

- Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 07.01.2002, № 1, 1 статья);

- Россия Федерациясе Торак кодексы (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 03.01.2005, № 1, 14 статья);

- «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 214-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 03.01.2005, № 1, 40 статья);

- «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 08.05.2006, № 19, 2060 статья);

- «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 29.12.2008, № 52, 6249 статья);

- «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 31.07.2006, № 31, 3451 статья);

- «Төзүчеләрнең түләргә хәле җитмәгәндә (бөлгенлеккә төшкәндә) өлешләп төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 218-ФЗ номерлы Федераль закон) (Российская газета, № 169, 2017 елның 2 августы);

- «Төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгы нормативлары турында» 2018 елның 26 декабрендәге 1683 номерлы РФ Хөкүмәте карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 28.12.2018);

- «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү Кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 12.07.2010, № 28, 3706 статья);

- «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек турында» 2021 елның 6 мартындагы 338 номерлы РФ Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 15.03.2021, №11, 1830 статья);

- «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга туры китереп, өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсе нигезендә күпфатирлы йортларны төзү (булдыру) өчен гражданнарның һәм юридик затларның акчаларын җәлеп итү хокукына ия булган төзүченең үз акчаларын исәпләү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 11 июнендәге 673 номерлы РФ Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 18.06.2018, № 25, 3693 статья);

- «Өлешләп төзүдә катнашу турындагы законнарда билгеләнгән өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсе буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен неустойка (штраф, пеня), башка финанс санкцияләр, шулай ук башка җаваплылык чаралары куллану үзенчәлекләрен билгеләү һәм аларга карата төзүче тарафыннан күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектын төзеп бетерү (төзү) вакыты һәм (яки) өлешләп төзүдә катнашуның теркәлгән шартнамәсе буенча өлешләп төзүдә катнашучыга өлешләп төзү объектын тапшыру буенча бурычлар 6 айдан артык бозылган күпфатирлы йортларның проблемалы объектлары һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектлары реестрына кертү үзенчәлекләре турында» 2020 елның 2 апрелендәге 423 номерлы РФ Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 13.04.2020, №15 (IV өлеш), 2280 статья);

- «Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм үткәрүгә таләпләрне раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге 1336 номерлы РФ Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 07.09.2020, №36, 5638 статья) ;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат алар карамагында булган оешмалардан тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлеге кысаларында соратыла һәм алына торган документлар һәм (яисә) мәгълүмат исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы күрсәтмәсе (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 02.05.2016, № 18, 2647 статья);

- Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы («Российская газета», 14.05.2009, № 85);

- Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Төзелешкә рөхсәт формасын һәм объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт формасын

раслау турында» 2015 елның 19 февралендәге 117/пр номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 13.04.2015)

- Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Проект декларациясе формасын раслау турында» 2016 елның 20 декабрендәге 996/пр номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 30.12.2016);

- «Күпфатирлы йортның торак-төзелеш кооперативын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында турында хисап формасын, шул исәптән мондый кооперативның кооператив әгъзалары һәм башка затлар алдында үз йөкләмәләрен үтәү һәм күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органына торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күрсәтелгән хисаплылык бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 3 июлендәге 955/пр номерлы Россия Төзелеш министрлыгы боерыгы, (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 27.10.2017);

- «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1.1 һәм 2 өлешләрендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә төзүченең һәм проект декларациясенең туры килүе турында бәяләмә формасын раслау турында» Россия Төзелеш министрлыгының 2018 елның 11 октябрендәге 653/пр номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 28.12.2018);

- Россия Төзелеш министрлыгының «Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру турында, шул исәптән шартнамә буенча төзелеш проектларын һәм үз йөкләмәләрен гамәлгә ашыруның якынча графикларын үтәү турында хисапны, төзелеш проектының җыелма тупланма ведомостен тикшерүче органга төзүчеләр тарафыннан бирү формаларын һәм тәртибен раслау турында» 2018 елның 12 октябрендәге 656/пр номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 21.02.2009);

- «Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының төзүчедән эшләр башкаручы, товарлар белән тәэмин итүче һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен, архитектура-төзелеш проектларын һәм төзелешне башкару буенча хезмәтләр күрсәтүче затлар турында, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр төрләре турында һәм әлеге затларның күрсәтелгән эш төрләре башкаруга, товарлар белән тәэмин итүгә һәм хезмәтләр күрсәтүгә тиешле рөхсәт (лицензия) булуы турында мәгълүмат алу тәртибе турында» 2019 елның 18 декабрендәге 820/пр номерлы Россия Төзелеш министрлыгы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 23.03.2020 ел);

- «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең

бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы, 28.12.2007, № 259);

- «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы, 03.08.2004, № 155-156);

- «Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативларының эшчәнлеген тикшереп торуны оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 8 апрелендәге 223 номерлы карары (Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 23.04.2021, № 31, 0786 ст.);

- «Җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелеш өчен гражданнар акчаларын җәлеп итә торган затлардан алган күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләр һәм (яисә) документлар исемлеге турында» 2013 елның 11 октябрендәге 750 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 18.10.2013, № 77, 2609 ст.);

- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль район Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы (алга таба - Устав);

- Түбән Кама муниципаль районы Советының 2020 елның 23 мартындагы 26 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба - БК турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш һәм архитектура идарәсе турында нигезләмә.

2. 3.12.3 - 3.12.7 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3.12.3. Төзүченең күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру, шул исәптән шартнамә буенча төзелеш проектларын һәм үз йөкләмәләрен гамәлгә ашыруның якынча графикларын үтәү турында хисабын, төзелеш проектының җыелма тупланма ведомостен, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисабын тикшерүче органга электрон документ рәвешендә бердәм торак төзелеше мәгълүмати системасында төзүченең шәхси кабинеты аша җибәрү (алга таба – БТТМС).

3.12.4. Хисап тикшерүче органга төзүче тарафыннан хисап чоры тәмамланганнан соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, тикшерүче органга төзүче тарафыннан IV

квартал тәмамланганнан соң 90 календарь көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла торган IV кварталдагы хисаптан тыш тапшырыла.

Хисап һәм аңа кушымталар хисап бирүче затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

Хисап бирү датасы булып, БТТМСта төзүченең шәхси кабинетында хисапларны урнаштыру датасы тора.

3.12.5. Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүчедән һәр квартал хисаплылыгын тикшерү буенча административ процедура БТТМСта төзүченең шәхси кабинетында әлеге хисап урнаштырганнан соң башлана.

3.12.6. Тикшерүче органның шәхси кабинетына хисап кергәннән соң, вәкаләтле хезмәткәр тикшерү үткәрә:

- төзүче тарафыннан өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына төзүченең квартал саен хисабы бирү срокларын һәм аның составына карата таләпләрне үтәү;

- төзүче тарафыннан өлешләп төзүдә катнашучылар акчаларын максатсыз файдалану билгеләре булу яки булмау;

- төзүче тарафыннан үз эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын бәяләү нормативларын үтәү;

- төзүче тарафыннан өлешләп төзүдә катнашучылар алдында шартнамә йөкләмәләрен үтәү срокларын үтәү;

- төзүче тарафыннан төзелеш проектларын тормышка ашыруның якынча графикларын үтәү;

3.12.7 Административ регламентның 3.12.6 пунктында күрсәтелгән бозуларны билгеләгәндә һәм Россия Федерациясе законнарында каралган документлар булмаганда, белгеч төзүчегә күрсәтмә җибәрә яисә Административ регламентка 2 нче кушымта нигезендә билгеләнгән формада тикшерү акты төзи.

Төзүчеләр тарафыннан тикшерүче органнардан документлар, күрсәтмәләр алу БТТМСта төзүченең шәхси кабинетын кулланып гамәлгә ашырыла.